# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ТҮБӘН СУЫК-СУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

« 03» апрель 2024 ел Түбән Суык-Су № 6

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче Түбән Суык-Су авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Советының 2019 елның 27 июнендәге 5/2 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче Түбән Суык-Су авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апреленә 13.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче Түбән Суык-Су авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү(балалар мәйданчыгы өчен балалар уены элементларын сатып алу, күпфатирлы йортлар территориясен төзекләндерү, ташуга каршы чаралар (траншеялар урнаштыру, туфрак өеме, агачлар кисү);

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, махсус техника хезмәте күрсәтү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары һәм комплектлау элементларын сатып алу);

- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, ремонт эшләре));

- Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү (бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү (сугышчыны буяу, яңарту));

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (күлне камышлардан чистарту);

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын инвентарен сатып алу һәм урнаштыру (гидрант, көпшә, җиңсә));

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү(балалар мәйданчыгы өчен балалар уены элементларын сатып алу, күпфатирлы йортлар территориясен төзекләндерү, ташуга каршы чаралар (траншеялар урнаштыру, туфрак өеме, агачлар кисү);

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, махсус техника хезмәте күрсәтү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары һәм комплектлау элементларын сатып алу);

- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, ремонт эшләре));

- Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү (бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү (сугышчыны буяу, яңарту));

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (күлне камышлардан чистарту);

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын инвентарен сатып алу һәм урнаштыру (гидрант, көпшә, җиңсә));

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Түбән Суык-Су авыл җирлеге, Түбән Суык-Су авылы, Үзәк ур., 1А йорт (Түбән Суык-Су мәдәният йорты бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлык урынбасары Д.З.Фазуллин